ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН! СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО - ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №146 (7319) | 5 декабрь, 1991 ел ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Бердәм тырышлык белән

РАЙОН ЭЛЕМТӘ УЗЕЛЫ. Коллектив әйбәт күрсәткечләргә ирешеп эшли. Соңгы ноябрь аенда элемтәчеләр планда каралган 219 мең урынына 270 мең 444 сумлык тариф кереме алдылар, шуның белән бу төр планны 123 процентка үтәделәр. Халыктан алынган керем планы да 113,3 процент итеп үтәлде.

Коллектив бу уңышка бердәм тырышлык нәтиҗәсендә иреште. Бигрәк тә почта элемтәчеләре (почта бүлекчәләре, сортировкалау һәм башкалар), шәһәр һәм шәһәрара телефон элемтәсе әйбәт күрсәткечләргә ирештеләр. Соңгы айда переводлар бүлекчәсенә дә эш күп булды. Флера Шәйдуллина һәм Мария Королеваның өлгерлеге, итагатьлелегенә чын күңелдән сокланырлык иде.

Авыл почта бүлекчәләреннән Мамык (Н. Р. Лизунова), 2 нче номерлы шәһәр (Р. С. Биктимерова), Кизләү (Х. Бакирова), Киекле (С. С. Минпекаева), Төрнәс (Н. Рябова) бүлекчәләре эше шулай ук мактауга лаек. 1 нче номерлы шәһәр элемтә бүлекчәсе дә өченче кварталда планда каралган 5441 сум урынына 6115 сумлык тариф кереме алды. Аның мөдире Раиса Михайловна Астрова безнең иң хөрмәтле, иң зур стажлы элемтәчеләребездән санала. 30 елдан артык шул системада хезмәт куйган ул.

**М. ЛЕТФУЛЛИНА.**



Раиса Григорьевна Тимакова (рәсемдә) — «Заветы Ильича» колхозында тәҗрибәле савучыларның берсе. Коллективта аны эшчән, гаҗәеп намуслы булуы өчен хөрмәт итәләр. Фермага башлап килгән яшьләр дә ярдәм-киңәш сорап күбрәк аңа мөрәҗәгать итәләр. Сабыр холыклы Раиса Григорьевна аларга хезмәт серләренә төшенергә теләп булыша. Быел ул беренче кат бозаулаган сыерлар сава, бу кыен чорда да маллардан мул продукция алырга тырыша.

Сүз уңаеннан, терлекчелек Тимаковлар өчен гаилә һөнәренә әверелде инде. Гаилә башлыгы Геннадий Архипович та шул ук фермада терлекче булып эшли.

## АЛДЫНГЫЛАР БЕЗДӘ ДӘ БАР

«АЛГА» КОЛХОЗЫ. Хуҗалык быел терлекчелектәге күрсәткечләре белән әлләни мактана алмый. Әмма шул шартларда да тырыш, уңган савучылар мул продукция алуга ирешәләр. 1 бригададан Зөлфия Дәүләтшина, мәсәлән, үз группасындагы малларның һәркайсыннан 11 айда 3465 әр килограмм сөт савып, колхоз савучылары арасында әйдәп бара. Алдынгыларның калган икесе дә шул ук бригададан — Зәйтүнә Кадыйрова һәм Зәбирә Мәхмүтова. Алар һәр сыерга 3271—2972 әр килограмм сөт җитештерделәр.

Колхозның ит җитештерүчеләре арасында Рауза Галиуллина белән Наилә Шәрәкова һәрьяклап мактауга лаеклар. Профилакторий группасындагы яшь бозаулардан ноябрь аенда 944 әр грамм тәүлеклек үсеш алдылар алар. II бригада терлекчесе Илдус Камаев үз карамагындагы 4 айдан зур 60 баш бозауның һәркайсыннан 720 шәр грамм үсеш алды.

**Х. ШАКИРОВА,**
бухгалтер.

## Эшләре сыйфатлы

«Төрнәс» совхозының үзәк ремонт мастерскоe һәм Төрнәс бүлекчәсенең машина-трактор паркында авыл хуҗалыгы машиналарына киләсе ел уңышын җыеп алуда ныклы ремонт үткәрүгә җитди әһәмият бирелә.

Механизаторлар һәр минутны отышлы файдаланып эшләргә тырышалар. Алар ярдәме белән чәчкеч, культиватор һәм тырмаларның байтагы ремонтланды инде.

Үзәк ремонт мастерскоеннан Владимир Титов, Хәниф Ишниязов, Анатолий Давыденко, Валентин Колотухин, Вячеслав Захаров, Евгений Денисов һәм Төрнәс бүлекчәсенең машина-трактор паркыннан Валерий Дмитриев, Александр Антонов, Алексей Аладин, Вячеслав Васиннарның эше һәрчак сыйфат белән башкарыла.

**Т. ВАРЛАМОВА,**
экономист.

## *Кара. Чагыштыр. Нәтиҗә яса.*

**Беренче багана — хуҗалыклар исемнәре, икенче — 1991 елның 11 аенда бер сыердан савылган сөт, өченче — 1990 елга карата артык яки ким (килограммнарда).**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Синдряков исем. | 2409 | — | «40 лет Победы» | 3243 | +252 |
| Ульянов исем. | 2873 | —172 | «Чишмә» | 2948 | —58 |
| «Правда» | 2342 | —64 | «Таң» | 3013 | —137 |
| «Восход» | 2721 | —192 | «Москва» | 2635 | —196 |
| Мичурин исем. | 3960 | —360 | «Үрнәк» | 3709 | —218 |
| «Россия» | 3183 | —37 | «Лесная Поляна» | — | — |
| Хафизов исем. | 2405 | —606 | «Кондырча» | 3342 | —180 |
| «Путь к коммунизму» | 3173 | —77 | Кузнецов исем. | 2333 | —79 |
| Муса Җәлил исем. | 2950 | —69 | «Заря» | 3455 | +252 |
| «Родина» | 2367 | —44 | «Чирмешән» | 3072 | —318 |
| «Игенче» | 2784 | —78 | «Ленинский путь» | — | — |
| «Большевик» | 3159 | —29 | «Беренче май» | 2399 | — |
| «Заветы Ильича» | 2822 | —75 | «Төрнәс» совхозы | 1939 | —292 |
| «Знамя Октября» | 2350 | +357 | «Мамык» совхозы | 2665 | —114 |
| «Алга» | 2118 | —416 | «Рассвет» совхозы | 3665 | +— |
| «Комбайн» | 2937 | —17 | «Сөлчә» совхозы | 2479 | —381 |
| XXI партсъезд исем. | 2672 | —187 | «Яшь көч» | 2448 | — |
| «Татарстан» | 3129 | —132 | Район буенча | 2778 | —130 |

## УКАЗ

### БЮДЖЕТ ОЕШМАЛАРЫНДА ҺӘМ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ ЭШЛӘҮЧЕЛӘРНЕҢ ЭШ ХАКЫН АРТТЫРУ ТУРЫНДА

Бюджеттан финанслана торган сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният оешмаларында һәм учреждениеләрендә эшләүчеләрнең социаль яклангалыгын көчәйтү максатында КАРАР БИРӘМ:

1. Сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният оешмаларында һәм учреждениеләрендә эшләүчеләрнең гамәлдәге тариф ставкалары һәм окладлары күләмен 1991 елның 1 декабреннән 100 процентка арттырырга.

Хезмәткә түләүнең шартларын, шулай ук тариф ставкалары һәм окладларны куллану тәртибен гамәлдәге положениеләрдә каралганча сакларга.

2. ТССР Министрлар Кабинетына бюджеттан финанслана торган башка оешмаларда, учреждениеләрдә һәм идарә органнарында эшләүче хезмәткәрләрнең эш хакларын арттыру күләмен ачыкларга һәм бу мәсьәлә буенча агымдагы елның 1 декабренә кадәр тиешле карар кабул итәргә.

3. ТССР Министрлар Кабинетына:

бу максатлар өчен чыгымнарны финанслауның тәртибен һәм чыганакларын ачыкларга;

хезмәткәрләрнең алда әйтеп кителгән категорияләренең хезмәтенә түләүне алга таба да камилләштерүне күздә тотарга.

**Татарстан Совет Социалистик Республикасы Президенты М. ШӘЙМИЕВ.**

Казан, 1991 ел, 27 ноябрь.

## Ишеттегезме әле...

### КЫЗЫЛ МӘЙДАНДА ҮЗ-ҮЗЕН ЯНДЫРЫРГА МАТАШУ

Күптән түгел Кызыл мәйданның күренекле урынында Дагестанның Дербент шәһәрендә яшәүче Гусейнов үз-үзен яндырырга маташа. Хокук саклау органнары хәбәр итүенчә, Гусейнов Канаданың СССРдагы илчесе аңа чит илгә чыгуга рөхсәт бирүдән баш тартуга бәйләп протест белдергән икән.

### НАЗАРБАЕВНЫҢ ҮЗ ВЕРТОЛЕТЫ БУЛАЧАК

Казахстан Президенты Нурсултан Назарбаев өчен персональ вертолетны махсус заказ буенча Казан вертолет берләшмәсе төзи. Бу «МИ-80»гә караганда дүрт тапкырга кыйммәтрәк — 4 миллионнан да артыграк булачак.

Азербайҗан, Татарстан җитәкчеләре дә президент вертолетлары төзү өчен заявкалар бирделәр.

### ЯҢА БӘЯЛӘР БУЕНЧА БЕРЕНЧЕ КӨН

Вологда өлкәсе администрациясе башлыгы Н. Подгорнов карары белән кертелгән яңа бәяләр вологжаннарга азык-төлек муллыгы китермәде. Бәяләр берничә тапкыр артса да — итнең килограммы 30, каймак — 6—10, бер шешә сөт — 1 сум 40 тиен — кибет киштәләре буш калды. Н. Подгорнов азык-төлек дефицитының төп сәбәбе итеп колхоз һәм совхозларның үз продукцияләрен арзан бәяләргә сатарга теләмәүләреннән дип исәпли.

## Ял кичәсе булды

Район яшь туристлар станциясе (РСЮТ) үз карамагындагы түгәрәкләргә йөрүчеләр өчен ял кичәсе оештырды. Кичәнең программасын төзүчеләр аны һәр түгәрәкнең үзенчәлеген күздә тотып башкарганнар иде. Үзешчән артистлар чыгышы да, туристик күнекмәләр буенча ярышта, рәсемнәр һәм кулдан ясалган әйберләр конкурсы да бик кызык булды. Ә жюри ял кичәсенә кунакка чакырылган ата-аналар арасыннан сайланды. Әмма арада иң кызыгы — «Могҗизалар кыры» дигән тамаша булды. Аны «Яшь тарихчы — туган якны өйрәнүче» түгәрәге җитәкчесе И. Л. Сандлер алып барды. Әлеге тамаша яшь тарихчылар, этнографлар, экологлар, фотографлар, яшь хәбәрчеләр һәм башкалар өчен дә бик кызыклы булды. «Могҗизалар кыры»ның финалында җиңеп чыгучы — «Җәяүле турист» түгәрәге члены Равил Шиһаповка (1 нче мәктәп) истәлекле бүләк тапшырылды. Кулдан ясалган әйберләр арасында иң ошаганы — Саша Маркелов (1 нче мәктәп) хезмәте булды. Рәсемнәр буенча «Солнышко» балалар бакчасының беренче сыйныфына йөрүче Катя Кузьмина җиңү яулады.

Мондый ял кичәләре бездә традициягә әверелеп бара.

**М. БИКМЕТОВА,**
район яшь туристлар станциясенең директор урынбасары.

# Атналык почтадан

## Ялгыз калмадылар

24 октябрьдә кичке сәгать сигезләр тирәсендә Яңа Әмзәдә Разия апа Якупова хуҗалыгында янгын чыкты. Йорт җиһазлары, терлекләре, ризыклары, кием-салымнары — һәммәсе кара күмергә әйләнде. Хәтта коткарырга да өлгерә алмадылар. Авылдашлар, җил дә исеп торганлыктан, ут күрше йортка үрләмәсен өчен бик тырыштылар. Янгын башкаларга күчсә, бәхетсезләр саны тагын да артачак иде.

Янгын булган көндә әлеге йортның хуҗасы Разия апа Якупова үзе Норлатта булган. Кунактан кайтышына өе урынында кара күмер хәрабәләр генә утырганын күргән кешенең хәлен чамалыйсыздыр. Әмма колхоз җитәкчелеге аны бу бәлада ялгыз калдырмады. Әлеге гаиләне вакытында колхоз йортына урнаштырдылар, ә киләчәктә аларга үз нигезләрендә йорт салырга булышачакларын вәгъдә иттеләр.

Авыл халкы да ярдәмнән ташламады, һәркем кулыннан килгәнчә аларның хәлен җиңеләйтергә тырышты. Разия апалар гаиләсе колхозга һәм авылдашларына олы рәхмәтләрен белдерәләр.

**С. ФӘТХЕТДИНОВА,**
«Комбайн» колхозы колхозчысы.

## ГАЗЕТАДА БАСЫЛМАСА ДА...

«Хөрмәтле редакция! Без Кизләү авылы халкы хәзерләүче булмаудан интегәбез. Сугап, бәрәңге җыюда тоткарлык булмады. Ә менә тире, йон һәм башка чималны тапшыра алмыйбыз, тиреләр бозылып, кибеп ята, йон сыйфатын югалта», — дип язалар Кизләү авылыннан бер төркем колхозчылар.

Хат тикшерү һәм чара күрү өчен хәзерләүләр конторасы директоры Ә. М. Шәйдуллинга юлланган иде.

«Әйе, кеше булмау сәбәпле Кизләү авылында хәзерләүче булмый торды. Бүгенге көндә анда Ильяс Сөләйманов эшли. Ул атнаның пәнҗешәмбе көнендә авыл хуҗалыгы продуктлары һәм икенчел чимал җыя. Иптәш Сөләйманов үзе Норлат шәһәрендә яши. Шуңа да продукт һәм чималларны Кизләү авылының Нәҗип Миннеәхмәтович Билданов йортында җыярга туры килә аңа», — дип җавап бирә иптәш Шәйдуллин редакциягә.

## • Бер колхоз хәбәрләре

Хуҗалыкта төп эшче куллар җитешмәгәндә, колхоз җитәкчеләре гадәттә пенсионерларга мөрәҗәгать итәләр. Андый чакта Анисим Алексеевич Максюткин беренчеләрдән булып ярдәмгә ашыга. Узган җәй дә ул механикалаштырылган ындыр табагында мөдир булып эшләде, басудан ындырга кайткан ашлыкны үзвакытында ышанычлы урнаштыру өчен көчен кызганмады, хәзер дә үтенеч төшкәндә беркемне кире бормый.



Рәсемдә: «Заря» колхозы хезмәт ветераны А. А. Максюткин.

## Яхшы нәтиҗәләргә ирешәләр

«Заря» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасы коллективы продуктны арттыруда үзләренә куелган максатка һәм бурычларга ирешү өчен агымдагы елда да зур тырышлык куеп һәм икеләтә энергия белән эшли.

Сыер савучылар арасындагы ярышта бүгенге көндә дә Зинаида Николаевна Ермошкина алдынгылыкны үз кулында тота. Ул ел башыннан һәр сыердан 3632 килограмм сөт сауды. Аннан соңгы урыннарны Галина Алексеевна Ермилова белән Надежда Николаевна Магушева үзара бүлешәләр. Аларның ел башыннан бер сыердан сауган сөтләре — 3395 — 3100 килограмм.

**Л. ЯКОВЛЕВА,**
экономист.

## Кече предприятие тамыр җәя

«Татжилгражданстрой» РСУсы каршында оештырылган кече предприятие хакында «Дуслык» газетасында хәбәр ителгән иде инде. Аның төп максаты халык соравы зур булган товарларны реализацияләү. Моны берничә төрле юнәлештә алып барабыз.

Шуларның беренчесе — халык куллануы товарларын үзебездә җитештереп сатабыз. Мисал өчен җиңел автомобильләргә резина втулкалар, йөк машиналарына двигатель подушкалары хәзерлибез. Сатуга шулай ук төрле үлчәмдәге рәсемле ишек пыялалары да чыгарыла. Асбесттан коелган матрешкаларны сувенир буларак бүләк итәргә мөмкин. Үзебездә чәчәкле кафель җитештерәбез, аны да халык теләп алыр дип ышанабыз.

Квартиралар, бакча йортлары өчен плинтуслар, рамалар, штакетниклар, тартмалар һәм башка төрле кирәк-яраклар да сатуга чыгарыла. Бер үк вакытта андый төр җиһазларны хәзерләү өчен заказлар да кабул итәбез.

РСУга кайтарылып та үзебездән арткан төзелеш материалларының да бер өлеше кече предприятие кибете аша сатуга чыгарыла. Бүгенге көндә, мәсәлән, керосин кибете янында урнашкан безнең салон-магазинда сатуда олифа, төрле төстәге эмаль һәм нейтроэмаль буяулар, коры штукатурка да бар. Шулай ук акшар һәм төзелеш өчен икмәк ролен үтәгән цементны да сатабыз. Хуҗалык товарлары кибетләрендә булмаган электр җиһазларының байтак төрләре дә сатуга куела.

Әйтергә кирәк, тормыш-көнкүреш өчен кирәкле бу товарларны сатуны киләчәктә дә дәвам иттерүне күздә тотабыз. Халык ихтыяҗын, сорауны өйрәнеп, үзебездә хәзерләргә мөмкин булган башка төр товарларны да сатуга чыгарырга исәп тотабыз.

Киләчәктә предприятиене үстерү юнәлешендә эш алып барыла. РСУ исәбенә аның базасын киңәйтү күздә тотыла. Аны махсус автомобиль белән тәэмин итү, заказларны үтәү өчен төрле һөнәр осталарын билгеләү предприятиенең эшен тагын да активлаштыра төшәр.

Бусы бер юнәлеш. Икенче яктан без халык соравы зур булган товарларны һәм җиһазларны, әйтик, кием-салым, радиоаппаратура, йорт җиһазлары кайтарту һәм аны сату юнәлешендә дә эш алып барырга исәплибез.

**Ф. ШӘЙДУЛЛИН,**
РСУ мастеры, кече предприятие директоры.

## Ферма уңганнары



Фермаларда бүген терлекләрне кышлату чоры бара. Аның ни дәрәҗәдә уңышлы булуы җәйдән салынган нигезнең ныклыгына бәйле. Мул азык базасы булдыру, фермаларны, азык цехларын төзәтеп, тәртипкә китерү — болар барысы да бүгенге көндә малларның продуктлылыгын арттыру, шулай ук терлекчеләргә уңай эш шартларын тәэмин итүче алшартлар булып тора. Ә хезмәтеннән күңел канәгатьләнүе алу өчен көчеңне дә кызганмаска кирәк икәнен бик яхшы аңлыйлар терлекчеләр.

10 ай нәтиҗәләрен исәпләсәң «Путь к коммунизму» колхозы буенча бер сыердан 2729 килограмм сөт савып алынды. Биләр Озерода урнашкан 2 нче товарлыклы-сөтчелек фермасында бу күрсәткеч 3082 килограмм тәшкил итә.

Биредәге тату, тырыш коллективны Анна Наумовна Семенова җитәкли. Фермада иң алдынгы сыер савучы дигән мактаулы исемне Вера Васильевна Ханская йөртә. Ул ел башыннан группасындагы һәр сыердан 3704 килограмм сөт сауды.

Зоя Васильевна Маланчева да аңардан бик азга калыша. Аның күрсәткече 3607 килограмм. Ул гомере буе сыер савучы булып эшләп, гел алдынгылар рәтендә булды. Тырыш савымчының хезмәте елның-елында бүләкләргә лаек булды, районның Почет китабына теркәлде, фермага килгән күп кенә яшьләрнең остазы, беренче ярдәмчесе дә ул иде, (рәсемдә).

Надежда Николаевна Минькина да хезмәттәшләреннән калышмаска тырыша. Ул 3454 килограмм сөт сауды. Терлекләрнең сөтлелеге аларның ничек тәрбияләнүенә дә бәйле, әлбәттә. Валентин Куприн, Александр Белов исә бу җәһәттән эшләренә тел-теш тидерә торган терлекчеләр түгел.

1 нче Гэйтэн бригадасында ферма буенча бер сыерга 10 айга 2887 килограмм сөт туры килә. Ирина Глушкина, Марина Хворостьева, Валентина Герасимова бирედә сөт саву буенча хезмәттәшләрен әйдәп баралар. Дөрес, соңгы көннәрдә сыерлар ташлату сәбәпле, көнлек савым бераз кимеде. Ләкин терлекчеләр моны вакытлы күренеш дип саныйлар һәм ел ахырына сыерларның мул сөт бирәчәкләренә өметләнәләр.

**Л. ЕРЕПОВА,**
«Путь к коммунизму» колхозының профком рәисе.

## Олыларны олыласаң...

Түбән Норлат авылы мәктәбендә хезмәт һәм сугыш ветераннарының җыелышы булып узды. Җыелышта Кормыш авыл Советы рәисе вазифаларын башкаручы Минвәли Җәлалов, «Кондырча» колхозы рәисе Сәгыйть Ильмухин, авыл Советы депутатлары, сәүдә хезмәткәрләре, шәфкать туташлары катнашты. Җыелыш башта умарта күчен хәтерләтсә дә, иптәш Җәлаловның тыныч тавышы, кешеләргә булган игътибарлы карашы, олыларга булган ихтирамы кешеләрне тынычланырга, үзләре өчен генә түгел, ә ярдәмчесез калган карткорыларга ничек ярдәм итү турында уйланырга мәҗбүр итте. Җыелышта хәзергесе көндә пенсиясе 186 сумнан артмаган олыгайган, ялгызакларга азык-төлек алу өчен ай саен 90 сум пенсияләренә өстәмә түләү кертергә дигән карарга килделәр. Ә «Кондырча» колхозы рәисе — С. Ильмухин иң элек язгы чәчү, урак һәм көзге уңышны җыюда колхозга һәрвакыт булышулары өчен рәхмәт әйтеп, авылда хәзергесе вакытта 257 пенсионер икәнлеген һәм хәлдән килгәнчә аларның ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тырышуларын, үзләренең өй янындагы бәрәңге бакчасына башка культуралар чәчәргә рөхсәт итүләрен, ә бәрәңгене 0,50 гектар күләмендә кырга чәчү өчен колхоз җир бүлеп бирәчәген белдерде.

Авыл ветераннар советы рәисе Таһир абый Тәмаев инде үзен рәислек вазифасыннан азат итүләрен сорады. Аның үтенече канәгатьләндерелде. Биш кешедән торган авыл ветераннар советы төзелеп, аның рәисе итеп мәктәп директоры Мирза абый Хисмәтуллин сайланды.

Җыелыштан соң мәктәп ашханәсе пешекчеләре Әнисә Әюпова, Разия Әхмәдиева, колхоздан Гүзәл Монасыйпова олыларны мәҗлес өстәле янына чакырдылар. Хуш исле чәйләреннән, тәмле ризыкларыннан һәркем авыз итте. Хәммәтшәриф абый Әхмәдиев, үзе дә олы яшьтә булуына карамастан, кунакларны аяк өсте торып каршы алып, ачык йөз, ягымлы сүз белән күңелләрен күтәрде.

Түбән Норлат кибете сатучылары Нурисә Ибраһимова һәм Гүзәл Әюповалар Норлат шәһәрендә пешерелгән чәкчәкләр, бавырсаклар һәм башка милли ризыкларны мәктәптә күчмә буфетта саттылар.

Җыелыштан һәркем күңел нуры, җан җылысы алып китте.

**Т. АЛЯКИМОВА.**

